**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Чернышевского ул., д.23, г. Лаишево
422610

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Чернышевский урамы, 23 нче йорт
Лаеш ш. 422610

Тел: 8-(84378) -2-52-28 Факс: 8-(84378) -2-54-34
e-mail: Ispolkom.Laishevo@tatar.ru

---

**2023 елның 28 декабре** **4114 номер**

# КАРАР

**«Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:000000:2043 кадастр номерлы җир участогы территориясен планлаштыру проектын эшләү турында» Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 10 февралендәге 385 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында.**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 45 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, территорияне тотрыклы үстерүне тәэмин итү, планлаштыру структурасы элементларын (кварталлар, микрорайоннар, башка элементлар) бүлеп бирү, капиталь төзелеш объектлары урнашкан җир кишәрлекләре чикләрен, линия объектларын төзү һәм урнаштыру өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре чикләрен билгеләү максатларында, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты карар итә:

1. Татарстан Республикасы, Лаеш муниципаль районы, Нармонка авыл җирлеге адресы буенча урнашкан 16:24:000000:2043 кадастр номерлы җир участогы территориясен планлаштыру һәм чикләү проектына кызыл линияләрне үзгәртү өлешендә үзгәрешләр кертергә.

2. Әлеге карарны “Кама ягы” («Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитетының архитектура һәм шәһәр төзелеше бүлеге башлыгы А. П. Карсаловка йөкләргә.

**Җитәкче** **А.Ә. Нурмөхәммәтов**